**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Вахит авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Җину торак пункты　　　　№ 129　　　　«21» май 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Вахит авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы нигезләмәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон, Росреестрның 2023 елның 15 мартындагы П/0086 номерлы «Хуҗасыз күчемсез мөлкәтне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында»гы Боерыгы нигезендә

Вахит авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Вахит авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибен беркетелгән тәртиптә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районыныц рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис　　　　　　　　　　　　Әскәрова Г.И.